Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль
районы Балыклы-Чүкәй авыл җирлеге Советы

**КАРАР № 5**

Балыклы-Чүкәй авылы 10 февраль 2023 ел

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балыклы-Чүкәй авыл җирлеге Советының 2013 елның 29 июлендә кабул ителгән "Балык Бистәсе муниципаль районының Балыклы-Чүкәй авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның һәм муниципаль хезмәткәрләрнең үз чыгымнары, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында белешмәләр бирү турындагы нигезләмәне раслау хакында»гы 9 номерлы карарга үзгәрешләр кертү хакында

2022 елның 1 апрелендәге «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» №90-ФЗ Федераль законы, Татарстан Республикасының 2020 елның 26 декабрендәге “Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында” № 97-ЗРТ законы кабул ителү сәбәпле, 2008 елның 25 декабрендәге «Коррупциягә каршы көрәш турында» №273-ФЗ Федераль законның 12.1 маддәсенә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 40 маддәсенә тәңгәлләштереп, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Балыклы-Чүкәй авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балыклы-Чүкәй авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балыклы-Чүкәй авыл җирлеге Советының 2013 елның 29 июлендә кабул ителгән "Балык Бистәсе муниципаль районының Балыклы-Чүкәй авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның һәм

муниципаль хезмәткәрләрнең үз чыгымнары, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында белешмәләр бирү турындагы нигезләмәне раслау хакында»гы 9 номерлы карарга түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итргә:

“11. Җир кишәрлеге, башка күчемсез милек объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр (оешмаларның устав (туплау) капиталында катнашу өлешләре, пайлары) цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта сатып алу буенча средстволар алу чыганаклары турында белешмәләр, әгәр килешү суммасы муниципаль вазыйфаны биләүче затның гомуми керемннән яки муниципаль хезмәткәрнең, аның хатыны (ире)нең килешү башкарылар алдындагы соңгы өч ел эчендәге гомуми керемннән артса, "Интернет" челтәрендә муниципаль районның рәсми сайтында урнаштырыла, ә муниципаль районның рәсми сайтында бу мәгълүматлар булмаган очракта аларның соравы буенча массакүләм мәгълүмат чараларына бастырып чыгару өчен бирелә.».

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Балыклы-Чүкәй авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга:
Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Балыклы-Чүкәй авылы, Үзәк урамы, 8 нче йорт; Иске Арыш авылы, Үзәк урамы, 23А нче йорт;Керәшен Казысы авылы,Титов Урамы,11б йорт, Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында веб-адрес буенча: http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru һәм» Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталы " Интернет-мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru.

3.Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Балыклы-Чүкәй авыл
җирлеге башлыгы И.С.Мазитов